| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ЗАРЕЧЕНСК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.01.2016 нче ел Яңа Зареченск авылы № 21

Яңа Зареченск авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Яңа Зареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының 2014 елның 25 февралендәге 61 номерлы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2016 елның 13 мартына Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2016 елда Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?:

- Яңа Зареченск, Таллы Күл, Дмитриевка, Измайлово, Николашкино авылларындагы зиратларны төзекләндерү - 149000 (кырык тугыз мең) сум.;

- Яңа Зареченск авыл җирлегендә юлларны чистарту, 10000 (ун мең) сум.;

- Измайлово, Яңа Зареченск бистәләрендә су насослары станцияләре территориясен төзекләндерү -10000 (ун мең) сум.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карар Яңа Зареченск авыл җирлегенең рәсми сайтында, Яңа Зареченск авыл җирлегенең Яңа Зареченск поселогы, мәдәният йорты бинасы, Вахитов урамы, 15 нче йорт, Николашкино авылы, Совет урамы, 38А йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында да урын алган.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы, Яңа Зареченск
авыл җирлеге Советы Рәисе С.Н. Багижева